Государственное автономное профессиональное

образовательное учреждение

«Мамадышский политехнический колледж»

УТВЕРЖДАЮ
Заместитель директора по ТО
__________Ахметшина А.Д.
«01» ____09____ 2025 г.

РАБОЧАЯ ПРОГРАММА

общеобразовательной дисциплины

ОД.14 Родной язык (татарский)

для специальности

43.02.15. Поварское и кондитерское дело

2025

Рабочая программа учебной дисциплины разработана на основе:

- Федерального государственного образовательного стандарта (далее - ФГОС) по специальности среднего профессионального образования (далее - СПО) 43.02.15. Поварское и кондитерское дело, утвержденного приказом Минобрнауки России от 14.04.2022 г. № 235 (зарегистрированным Минюстом России 24.05.2022 № 68567);
- Федерального государственного образовательного стандарта среднего общего образования, утвержденного приказом Министерства образования и науки Российской Федерации от 12 мая 2019 г. №413 (в редакции от 12 августа 2022);
- Федеральной образовательной программы среднего общего образования, утвержденной приказом Минпросвещения России от18.05.2023г.№371 (зарегистрированного в Минюсте России 12.07.2023 №72428);
- Примерной рабочей программы общеобразовательной учебной дисциплины «Родной язык (татарский)» для профессиональных образовательных организаций, утвержденной Советом по оценке содержания и качества примерных рабочих программ общеобразовательного и социально-гуманитарного циклов среднего профессионального образования ФГБОУ ДПО ИРПО Протокол № 14 от «30» ноября 2022 г.

Обсуждена и одобрена на заседании
предметно-цикловой комиссии
общеобразовательных дисциплин

Разработала преподаватель:
_________ А.Д. Ахметшина

Протокол № 1

«28» августа 2025 г.

Председатель ПЦК _________ Н.С. Порываева

**ЭЧТӘЛЕК**

**УКУ ФӘНЕНЕҢ ЭШ ПРОГРАММАСЫ ПАСПОРТЫ...............................4**

**УКУ ФӘНЕНЕҢ ЭЧТӘЛЕГЕ.........................................................................8**

**УКУ ФӘНЕН ТОРМЫШКА АШЫРУ ШАРТЛАРЫ.................................12**

**УКУ ФӘНЕН ҮЗЛӘШТЕРҮНЕ ТИКШЕРҮ ҺӘМ БӘЯЛӘҮ....................14**

## 1.Уку фәненең эш программасы паспорты
## “Туган тел”

### 1.1. Программаны куллану өлкәсе:

«Туган тел» укыту дисциплинасының эш программасы төп һөнәри белем бирү программасының бер өлеше булып 43.02.15. Пешекче һәм кондитер эше белгечлеге тора.

### 1.2. Төп һөнәри белем бирү программасы структурасында дисциплина урыны:

"Туган тел" укыту дисциплинасы ОПОПның гомуми белем циклына керә.

Көллияттә татар теленә гуманитар предметлар рәтеннән беренчел дәрәҗәдәге әһәмият бирелә, ул ана телендә укытыла торган башка фәннәрне өйрәнү теле дә, укучыларның рухи дөньясын, әхлагын формалаштыруда әһәмиятле чара да. Ана теле ярдәмендә укучылар буыннар тәҗрибәсе белән тупланган мәдәният һәм сәнгать кыйммәтләре белән таныша, алардагы уңай сыйфатларны үзләштерә, укучыда туган җиренә мәхәббәт хисе тәрбияләнә.

Тел дәресләрендә, сүз сәнгате буларак, әдәби әсәрне аңлау һәм кабул итү дәрәҗәсе камилләшә. Татар теле дәресләрендә рус телен, чит ил телләрен өйрәнүгә дә нигез салына. Татар теле дәресләрендә танып белү, фикерләү сәләтен үстерүгә зур игътибар бирелә. Укучыларның акыл һәм иҗади сәләтләрен үстерү тәэмин ителә, хәтерләре һәм күзаллау дәрәҗәсе яхшыра, гомуми караш даирәсе үстерелә, мөстәкыйль уку эшчәнлеге күнекмәләре формалаша. Төрле белемнәрне үзләштерү һәм саклау формасы буларак, татар теле көллияттә укытыла торган башка предметлар белән тыгыз бәйләнештә тора һәм аларны үзләштерү сыйфатына уңай тәэсир итә.

**1.3. Дисциплинаның максатлары һәм бурычлары, - дисциплинаны үзләштерү нәтиҗәләренә карата таләпләр:**

«Туган тел» укыту дисциплинасының эчтәлеген үзләштерү студентлар тарафыннан түбәндәге нәтиҗәләргә ирешүне тәэмин итә:

- укучыларның сүзлек байлыгын арттыру, сөйләм һәм язма телен үстерү белән беррәттән, рухи дөньясын баету, реаль чынбарлыкка дөрес караш формалаштыру, тормыш вакыйгаларына хәбәрдарлыгын тәэмин итү;

- татар теленнән алынган теоретик материалны (тел системасын) аңлап үзләштерүне һәм тел фәнен яхшы белүне тәэмин итү;

-гамәли тел материалларын хәтердә калдырып һәм тәрбияви максатны күздә тоткан хәлдә, изложение һәм сочинениеләрне логик фикерләп, телдәге сурәтләү чараларын дөрес һәм урынлы кулланып, грамоталы итеп һәм дөрес каллиграфия белән яза белүләренә ирешү;

- идея дәрәҗәсенең югары булуын тәэмин итү;

-текст өстендә эшләү күнекмәләрен камилләштерү, үзеңнең һәм иптәшләреңнең кылган гамәлләренә дөрес бәя бирү;

- информация чыганакларыннан кирәкле мәгълүматларны таба һәм куллана белергә өйрәтү;

-укучыларда дәреслек һәм өстәмә әдәбияттан (әдәби әсәрләре, фәнни чыганаклар, төрле сүзлекләр, вакытлы матбугат) дөрес файдалану күнекмәләрен үстерү;

- план, тезис, конспектлар төзү, эш кәгазьләрен (деловые бумаги) дөрес һәм грамоталы язарга өйрәтү;

- бәйләнешле сөйләм культурасын үстерү өчен, укучыларда укыганны һәм сөйләгәнне кабул итү, сөйләмнән урынлы файдалану осталыгын (уку,язу,сөйләү,тыңлау, аңлау, сөйләшү, аралашу, диалогик һәм монологик сөйләм) иҗади эш башкару күнекмәләрен формалаштыру һәм үстерү.

**Белем дәрәҗәсе таләпләре:**

Укучыларның үзләштерергә тиешле белем – күнекмәләре:

1. Фонетика, лексика тармаклары турында, сузыкларга һәм тартыкларга хас орфоэпик һәм орфографик нормаларны белү, аваз үзгәрешләренә аңлатма бирә белү.
2. Татар теленең сүзлек составын белү. Лексикография буенча тулы мәгълүмат бирә белү.
3. Сүз төзелеше, сүз ясалышы, кушымчалар турындагы белемнәрне ныгыту.
4. Сүз төркемнәре. Синтаксис буенча тулы мәгълүмат алу.
5. Язу тарихын тирән белү.

Сөйләм эшчәнлегенә таләпләр:

1. Орфография, орфоэпия нормаларын үзләштерү, фонетик анализ ясый белү.
2. Төрле сүзлекләрдән файдалану күнекмәләрен булдыру.
3. Сөйләмдә сүз төркемнәреннән дөрес һәм урынлы файдалану, төгәл итеп анализлау
4. Сүзләргә фонетик, морфологик, синтаксик анализ ясый белү күнекмәләрен булдыру, анализ үрнәкләрен камил белү.
5. Сүз ясалышын, төзелешен, сүзтезмәләрне тикшерү үрнәкләрен камил белү.
6. Орфографик прициплар һәм аларның нормаларын белү.
7. Стилистика һәм сөйләм культурасы нормаларын төгәл белү.
8. Пунктуация кагыйдәләреннән дөрес файдалану.
9. Сөйләм эшчәнлеге буенча тулы мәгълүматлы булу.

## 2. Уку дисциплинасының эчтәлеге һәм структурасы

**Туган тел**

| **Укыту эшләре төре** | **Сәгать саны** |
|---|---|
| **Укытучы белән берлектәге шөгыль** | **36** |
| Үзлектән эш | 0 |
| **Уку программасы күләме** | **36** |
| **Шул исәптән:** | |
| *Теоретик уку* | *8* |
| *Практик эш* | *26* |
| *Йомгаклау аттестациясе – дифференцированный зачет* | *2* |

## 2.1. «Туган тел» дисциплинасының эчтәлеге һәм тематик планы

| Разделы рабочей программы дисциплины | Содержание учебного материала, практических работ, самостоятельной работы студентов | Объем часов |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| **1нче бүлек** | **Тел – аралашу чарасы, иҗтимагый һәм сәяси күренеш** | **2** |
| Тема 1.1. | Кереш. Кеше тормышында туган телнең роле. Тел - аңлашу,аралашу чарасы, иҗтимагый, сәяси күренеш. Туган телдә әхлакый – рухи традицияләр чагылышы. Туган тел һәм һөнәр (лекция-әңгәмә) | 2 |
| **2 нче бүлек** | **Фонетика.** | **2** |
| Тема 2.1.<br>Тема 2.2. | Сузык һәм тартык авазлар, аларның үзгәрешләре. Басым. Интонация (лекция) | 1 |
| | Сүзләргә фонетик-график анализ ясау тәртибе (практик дәрес) | 1 |
| **3 нче бүлек** | **Сүз ясалышы һәм сүз төзелеше.** | **2** |
| Тема 3.1.<br>Тема 3.2. | Сүзнең мәгънәле кисәкләре. Кушымчаларның функцияләре. Сүз ясалышын тикшерү тәртибе (практик дәрес) | 2 |
| **4нче бүлек** | **Лексикология** | **4** |
| Тема 4.1. | Лексикология (лекция) | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| Тема 4.2.<br>Тема 4.3.<br>Тема 4.4. | | |
| | Синонимнар. Антонимнар. Күп мәгънәле сүзләр (практик дәрес) Фразеология. Татар теленең сүзлек составы. Омонимнар (практик дәрес) | 3 |
| **5 нче бүлек** | **Морфология** | **11** |
| Тема 5.1. | Морфология (лекция) | **1** |
| | **Исем** | **1** |
| Тема 5.2 | Исемнәрнең ясалышы. Исемнәрнең килеш, тартым, сан белән төрләнүе. Изафә бәйләнеш. Исем сүз төркеменә морфологик анализ (практик дәрес) | 1 |
| | **Сыйфат** | **2** |
| Тема 5.3.<br>Тема 5.4. | Сыйфат дәрәҗәләре. Сыйфатларның ясалышы ягыннан төрләре. Сыйфат сүз төркеменә морфологик анализ (практик дәрес) | 2 |
| | **Сан** | **1** |
| Тема 5.5. | Сан төркемчәләре. Саннарның ясалышы<br>Сан сүз төркеменә морфологик анализ (практик дәрес) | 1 |
| Тема 5.6. | **Алмашлык** | **1** |
| | Алмашлыклар. Алмашлыкларның килеш белән төрләнеше. Алмашлык сүз төркеменә морфологик анализ (практик дәрес) | 1 |
| Тема 5.7. | **Фигыль** | **3** |
| Тема 5.8. | Затланышлы, затланышсыз (сыйфат фигыль, хәл фигыль, инфинитив, | 3 |

| | | |
|---|---|---|
| Тема 5.9. | исем фигыль) фигыльләр. Фигыль төркемчәләре. Фигыльләргә морфологик анализ ясау тәртибе (практик дәрес) | |
| Тема 5.10. | **Рәвеш** | **1** |
| | Рәвеш. Рәвеш төркемчәләре. Рәвеш сүз төркеменә морфологик анализ ясау (практик дәрес) | 1 |
| Тема 5.11. | **Ярдәмлекләр** | **1** |
| | Бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр, кисәкчәләр, теркәгечләр (практик дәрес) | 1 |
| **6нчы бүлек** | **Татар әдәби теленең функциональ стильләре.** | **3** |
| Тема 6.1. | Татар әдәби теленең функциональ стильләре (лекция) | 1 |
| Тема 6.2<br>Тема 6.3. | Фәнни стиль. Эш кәгазьләре стиле (практик дәрес) | 2 |
| **7 нчы бүлек** | **Синтаксис** | **10** |
| Тема 7.1. | Синтаксис (лекция) | 1 |
| Тема 7.2. - 7.4. | Сүзтезмә һәм тезмә сүз. Гади җөмлә төрләре.<br>Җөмләнең баш кисәкләре (ия, хәбәр), җөмләнең иярчен кисәкләре (практик дәрес) | 3 |
| Тема 7.5-7.8. | Кушма җөмлә төрләре. Тезмә кушма җөмләләр. Иярченле кушма җөмләләр. Эндәш сүзләр, кереш сүзләрнең җөмләдәге урыны (практик дәрес) | 4 |

| | | |
|---|---|---|
| Тема 7.9. | Текст. Туры һәм кыек сөйләм (лекция) | 1 |
| Тема 7.10. | Текст. Туры һәм кыек сөйләм (практик дәрес) | 1 |
| | **Промежуточная аттестация (дифференцированный зачёт)** | **2** |
| | **Всего:** | **36** |

## 3. Уку фәнен тормышка ашыру шартлары

### 3.1. Минималь материаль – техник тәэмин ителешкә таләпләр

Фән программасы тормышка ашыру кабинет булуны таләп итә: Туган тел һәм әдәбияты кабинеты.

Уку кабинетының җаһазлары: язу тактасы, кием шкафы, китап шкафы, өстәл (укучылар өчен), өстәл (укытучылар өчен), урындыклар.

**Белем бирүнең техник чаралары:**

| № п\п | Наименование ТСО | Марка | Инв. № |
|---|---|---|---|
| 1. | Ноутбук портативный ПЭВМ | RAYbook Bi1010 ICL | 222101045654 |
| 2. | Программно – аппаратный комплекс | RAY S222Mi | 222101043067 |
| 3. | Доска интерактивная | TruBoard R3-1000 | 222101045755 |
| 4. | Проектор стационарный потолочное крепление | ViewSonic PA503S | 222101045756 |
| 5. | Беспроводная точка доступа | Cisco AIR – AP 18321 – RK9 (Нидерланды) | 0000003845 |

## Кулланылган әдәбият:

1. Татар теле: рус телендә урта гомуми белем бирү оешмалары 10 сыйныфы өчен уку әсбабы (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Р.К. Сәгъдиева. – Казан: «Мәгариф – Вакыт» нәшр., 2018. – 175 б.

2. Татар теле: рус телендә урта гомуми белем бирү оешмалары 11 сыйныфы өчен уку әсбабы (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Р.К. Сәгъдиева. – Казан: «Мәгариф – Вакыт» нәшр., 2018. – 195 б.

***Дополнительные источники:***

1. Татар әдәбияты: рус телендә урта гомуми белем бирү оешмалары 11 сыйныфы өчен уку әсбабы (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Ф.Ф. Хәсәнова, Г.М. Сафиуллина, Л.Ф. Җамалиева, Г.М. Әхмәтҗанова. – Казан: «Мәгариф – Вакыт» нәшр., 2018. – 383 б.

2. Русско-татарский словарь. Русча-татарча сүзлек. / авт.-сост.: Ф.А. Ганиев, Ф.Ф. Гаффарова. – Казань: Татар кн. изд-во, 2014. – 465 с.

3. Математический русско-татарский толковый словарь. // Математикадан русча-татарча аңлатмалы сүзлек. / (авт.-сост.: Л.И. Галиева, И.Г. Галяутдинов, М.З. Хуснетдинов и др.); под общ. ред. Л.И. Галиевой и И.Г. Галяутдинова. –Казань:Татар кн. изд-во, 2014. –254 с.

4. Татар теленең орфографик сүзлеге.Орфографический словарь татарского языка. / авт.-сост.: К.Р. Галиуллин, Р.И. Раскулова. –Казань: Татар кн. изд-во, 2017. – 423 с.

***Интернет-ресурсы:***

http:http://tt.wikipedia.org
http://tatarplanet.ru
http://belem.ru
http://www.kitap.net.ru
http://znanium.com/, электронно-библиотечная система
http://KnigaFond
edu.tatar.ru

## 4.Туган тел фәнен үзләштерүнең нәтиҗәсен тикшерү һәм бәяләү

| **Укыту нәтиҗәсе**<br>**( белергә, эшләргә тиеш)** | **Уку нәтиҗәләрен тикшерү һәм бәяләү формалары һәм алымнары** |
|---|---|
| **Укучыларның үзләштерергә тиешле белем – күнекмәләре:**<br>1. Фонетика, лексика тармаклары турында, сузыкларга һәм тартыкларга хас орфоэпик һәм орфографик нормаларны белү, аваз үзгәрешләренә аңлатма бирә белү.<br>2. Татар теленең сүзлек составын белү. Лексикография буенча тулы мәгълүмат бирә белү.<br>3. Сүз төзелеше, сүз ясалышы, кушымчалар турындагы белемнәрне ныгыту.<br>4. Сүз төркемнәре. Синтаксис буенча тулы мәгълүмат алу.<br>5. Язу тарихын тирән белү.<br>**Сөйләм эшчәнлегенә таләпләр:**<br>1. Орфография, орфоэпия нормаларын үзләштерү, фонетик анализ ясый белү.<br>2. Төрле сүзлекләрдән файдалану күнекмәләрен булдыру.<br>3. Сөйләмдә сүз төркемнәреннән дөрес һәм урынлы файдалану, төгәл итеп анализлау<br>4. Сүзләргә фонетик, морфологик, синтаксик анализ ясый белү күнекмәләрен булдыру, анализ үрнәкләрен камил белү.<br>5. Сүз ясалышын, төзелешен, сүзтезмәләрне тикшерү үрнәкләрен камил белү.<br>6. Орфографик прициплар һәм аларның нормаларын белү.<br>7. Стилистика һәм сөйләм культурасы нормаларын төгәл белү.<br>8. Пунктуация кагыйдәләреннән дөрес файдалану. | Тестлар; реферат; сорауларга җавап бирү; күнегүләр эшләү; конспектлар төзү; тәрҗемә итү; |